ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

29 декабрь **2021 ел** **№** 2301

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларында агымдагы һәм капиталь ремонт эшләрен кабул итү комиссиясен төзү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 94 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексы, Арча муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларында агымдагы һәм капиталь ремонт башкарылганнан соң эшләрне кабул итүне оештыру максатыннан, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларында агымдагы һәм капиталь ремонт эшләрен кабул итү комиссиясен төзергә (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларында агымдагы һәм капиталь ремонт эшләрен кабул итү комиссиясе турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Мөхәрәмов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
29.12.2017ел, № 2301
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларында агымдагы һәм капиталь ремонт эшләрен кабул итү комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

Комиссия рәисе:

Галимуллин И.Ә. - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;

Комиссия рәисе урынбасары:

Фазылов Р.Р. - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;

Комиссия секретаре:

Голубева Д. В. - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;

Комиссия әгъзалары:

1.Подряд оешмасы вәкиле (килешү буенча);

2.Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары белән сайланган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре вәкиле (килешү буенча);

3.Капиталь төзелеш объектының баланс тотучысы (милекчесе) вәкиле (килешү буенча);

4. Чакырылган экспертлар (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
29.12.2021ел, №2301
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларында агымдагы һәм капиталь ремонт эшләрен кабул итү комиссиясе турында нигезләмә**

**(алга таба - Нигезләмә)**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларында агымдагы һәм капиталь ремонт эшләрен кабул итү тәртибен билгели (алга таба - Комиссия).

1.2. Комиссия даими эшли торган булып тора.

1.3. Комиссия үз эшендә ведомство төзелеш нормаларына, торак биналарына капиталь ремонт тәмамланган йортларны файдалануга кабул итү кагыйдәләренә (ВСН 42-85(р)) һәм коммуналь һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар биналарын реконструкцияләү, ремонтлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү турындагы нигезләмәгә, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә кулланыла торган һәм гамәлдә булган башка норматив һәм техник документациягә, муниципаль контракт шартларына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары һәм хокуклары

2.1. Комиссиянең төп бурычлары:

- тикшерү өчен Комиссия әгъзаларына бирелгән биналарның аерым элементларын агымдагы һәм капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне кабул итү (түбәләр, фасадлар, тышкы коммуникацияләр, тышкы төзекләндерү, инженерлык җиһазларының аерым төрләре яки яисә проектлау һәм смета документларында башка төзелеш элементларын ремонтлау каралмаган шартларда шундый берничә элементның кушылмасы);

- подряд оешмасы тарафыннан бирелгән агымдагы һәм капиталь ремонт үткәрү документлары нигезендә башкарылган ремонт эшләрен тикшерү.

2.2. Күрсәтелгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- тиешле документларны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

- подряд оешмасы тарафыннан тапшырылган хисап документларына һәм материалларына анализ ясарга;

- кирәк булганда, подряд оешмасыннан җитешми торган хисап документларын һәм материалларны соратып алырга, шулай ук тапшырылган документлар һәм материаллар буенча аңлатмалар алырга;

- уздырылган товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне кабул итү нәтиҗәләре буенча карар кабул итәргә.

**3. Комиссиянең составы, вәкаләтләре һәм эш тәртибе**

3.1. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзалары керә.

3.2. Комиссия эшчәнлеген Комиссия рәисе, ул булмаганда, Комиссия рәисе урынбасары оештыра.

3.3. Секретарь Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итә.

3.4. Комиссия составына Арча муниципаль районы Башкарма комитеты, иҗтимагый оешмалар, берләшмәләр, җәмәгатьчелек вәкилләре керә.

3.5. Комиссия утырышта (кабул иткәндә) Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 2/3 булса, карар кабул итәргә хокуклы.

3.6. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларын агымдагы һәм капиталь ремонтлау эшләрен кабул итү аларның саны, комплектлылыгы, күләме, сыйфаты һәм куркынычсызлыгы муниципаль контрактларда билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

3.7. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларына агымдагы һәм капиталь ремонт ясау эшләрен кабул итү барлык ремонт эшләрен башкарганнан соң, шулай ук барлык кимчелекләрне һәм җитешсезлекләрне бетергәннән соң башкарылырга тиеш. Файдалануы махсуслаштырылган оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган газ, җылылык, электр, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектларында капиталь ремонт тәмамланган объектларны эксплуатациягә алганда, кабул итү комиссиясе составына өстәмә рәвештә әлеге оешмалар вәкилләрен кертергә тәкъдим ителә.

3.8. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларын агымдагы һәм капиталь ремонтлау эшләрен кабул итү датасы итеп, әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш

объектларының агымдагы яисә капиталь ремонт тәмамланганын кабул итү актына кул кую датасын санарга кирәк.

3.9. Комиссия әгъзалары башкарылган яшерен эшләрне тикшереү өчен аерым конструкцияләрне һәм (яисә) аларның төеннәрен ачарга, шулай ук аерым конструкцияләр һәм системалар сынауларын билгеләргә хокуклы.

3.10. Башкарылган эшләрне тикшерү өчен тәкъдим ителгәннәрне тикшергәндә, Комиссия әгъзаларының кисәтүләре булмаган очракта, Комиссиянең барлык чакырылган әгъзалары тарафыннан имзаланган башкарылган эшләрне кабул итү акты төзелә.

3.11. Комиссия әгъзаларының берсендә аерым фикер (кисәтү) булган очракта, Комиссия секретаре тарафыннан аерым фикерне теркәп, әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә тикшерү акты төзелә, анда ачыкланган кисәтүләрне бетерү сроклары һәм вакыты күрсәтелә. Әлеге срок тәмамлангач, Комиссия яңадан җыела һәм башкарылган эшләрне кабул итү турындагы мәсьәләне хәл итә.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы территориясендә
капиталь төзелеш объектларынд агымдагы
һәм капиталь ремонт эшләрен кабул итү комиссиясе
турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә агымдагы һәм капиталь ремонт тәмамланган капиталь төзелеш объектларын файдалануга кабул итү**

**АКТЫ**

"___" ____________ 20__ел ________________________________________

(бинаның урнашкан урыны)

____________ 20____ ел, № ___ карары белән расланган комиссия

______________________________________________________________________

(комиссияне билгеләп куйган органның исеме)

түбәндәге составта:

рәис_____________________________________________

(ф.и.а.и, вазифа)

секретарь________________________________________

(ф.и.а.и, вазифа)

һәм комиссия әгъзалары: ________________________________________________

(ф.и.а.и, вазифа)

______________________________________________________________________

(ф.и.а.и, вазифа)

_______________________________________________

(ф.и.а.и, вазифа)

_______________________________________________

(ф.и.а.и, вазифа)

билгеләде:

1. Подрядчы тарафыннан____________________________________

(исемен күрсәтергә)

агымдагы һәм / яки капиталь ремонт тәмамланган бина эксплуатациягә кабул итүгә карата бина___________________________________________________________

(бинаның урынын һәм билгеләнешен күрсәтергә)

2. Түбәндәге эшләр төрләре кабул итүгә тәкъдим ителде:

______________________________________________________________________

(эшләр исемен күрсәтергә)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

3. Агымдагы һәм капиталь ремонтка проект-смета документациясе эшләнде

_______________________________________________________________

(проект оешмасының исемен һәм аның ведомство буйсынучанлыгын күрсәтергә)

һәм расланды _______________________________________

(проект-смета документациясен раслаган органның исемен күрсәтергә)

4. Ремонт-төзелеш эшләре түбәндәге срокларда башкарылды:

эшләр башлану_______________________,

эшләр тәмамлану ________________________

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә капиталь төзелеш объектларын агымдагы һәм капиталь ремонтлау эшләрен кабул итү комиссиясе тикшерүе нигезендә түбәндәге карар кабул ителде:_________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

Үзенчәлекле фикер: ___________________________________________

Комиссия рәисе: ______________________________________________

(имза, ф.и.а.и.)

Комиссия секретаре: ___________________________________________

(имза, ф.и.а.и.)

Комиссия әгъзалары:___________________________________________

(имза, ф.и.а.и.)

_______________________________________________________________

(имза, ф.и.а.и.)

_______________________________________________________________

(имза, ф.и.а.и.)

_______________________________________________________________

(имза, ф.и.а.и.)

_______________________________________________________________

(имза, ф.и.а.и.)

СОГЛАСОВАНО
Глава Арского муниципального района
______________________ И.Г. Нуриев
«____» ______________ 2021 г.

**ЛИСТ СОГЛАСОВАНИЯ**
**к постановлению исполнительного комитета**
**Арского муниципального района Республики Татарстан**

1. Наименование документа **О создании комиссии по приемке работ по текущему и капитальному ремонту объектов капитального строительства на территории Арского муниципального района Республики Татарстан**

2. Проект подготовлен Отдел по юридическим вопросам
наименование отдела, учреждения, должностного лица

3. Исполнитель О.Г.Митина ____________ ____________
Ф.И.О подпись дата

4. Визы должностных лиц структурных подразделений о согласовании документа

| **Должность согласующего** | **Ф.И.О.** | **Подпись** | **Дата** |
|---|---|---|---|
| Первый заместитель руководителя исполнительного комитета | И.А.Галимуллин | | |
| Начальник отдела по юридическим вопросам | Л.Г.Сагитова | | |

Документ зарегистрирован: №2301 от 29 декабря 2021 г.